МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

31.10.2017 г. Казань № 959 од

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2017 елның 26 апрелендә имзаланган “Татарстан Республикасы территориясендә булган Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышын дәүләти контрольдә тоту буенча Административ регламентын раслау турында”гы 337 од номерлы боерыкка үзгәрешләр кертү турында

**БОЕРАМ:**

“Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә булган Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышын дәүләти контрольдә тоту буенча Административ регламентны раслау турында”гы Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгың 2017 елның 26 апрелендә имзаланган 337 од номерлы боерыгына (алга таба - Боерык), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерыкның атамасын түбәндәгечә язарга:

“Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә булган Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышын дәүләти контрольдә тоту буенча дәүләт функцияләрен үтәүнең Административ регламенты раслау турында”;

1нче пунктта “Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышын контрольдә тоту буенча” сүзләрен “Россия Федерациясе музей фондының дәүләт өлешк торышын дәүләти контрольне башкару буенча” сүзләре белән алмаштырырга;

Боерык белән расланган Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә булган Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышын дәүләти контрольдә тоту буенча дәүләт функцияләрен үтәүнең Административ регламентында (алга таба – Административ регламент):

Административ регламент атамасында “Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышын контрольдә тоту буенча” сүзләрен “Россия Федерациясе

музей фондының дәүләт өлешк торышын дәүләти контрольне башкару буенча” сүзләре белән алмаштырырга;

1.4 пунктын түбәндәгечә язарга:

“1.4 Дәүләт функциясе түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турындагы кодексы (алга таба – КоАП РФ), (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы 2002, № 1, 1нче бит, кертелгән үзгәрешләрне кертеп);

1992 елның 9 октябрендә кабул ителгән № 3612-1 Россия Федерациясе Законнары нигезләре (Ведомости Съезда народных депутатов Российской Федерации и Верховного Совета Российской Федерации, 1992, № 46, 2615 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Россия Федерациясенең 1993 елның 15 апрелендә кабул ителгән “Мәдәни мирасны чыгару һәм кертү турында”гы № 4804-1 законы (Ведомости Съезда народных депутатов Российской Федерации и Верховного Совета Российской Федерации, 1993, № 20, 718 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

1996 елның 26 маенда кабул ителгән “Россия Федерациясенең музе фонды һәм Россия Федерациясендә музейлар турында”гы № 54-ФЗ Федераль законы (алга таба – Федераль закон № 54-ФЗ) (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 1996, № 22, 2591 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

2006 елның 2 маенда кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”гы № 59-ФЗ Федераль законы (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 2006, № 19, 2060 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

2008 елның 26 декабрендә кабул ителгән “Дәүләт контролен (күзәтү) һәм муниципаль контроль үткәргән вакытта юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрне хокукларын яклау турында”гы № 294-ФЗ (алга таба - № 294-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 2008, № 52, 6249 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1998 елның 12 февралендә кабул ителгән №Россия Федерациясе Музей фонды, Россия Федерациясе музей фондының Дәүләт каталогы, Россия Федерациясендә музейлар эшчәнлеген лицензияләү турында”гы 179нчы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең № 179 карары) (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 1998, № 8, 949 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 30 июнендә кабул ителгән “Дәүләт контроль (күзәтү) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы тикшерү үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында”гы 489нчы карары (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 2010, № 28, 3706 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Россия Федерациясенең 2015 елның 28 апрелендә кабул ителгән “Бердәм тикшерүләр реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында”гы 415нче карары (Россия Федерациясе Законнары җыелмасы, 2015, № 19, 2825 бит);

Россия Федерациясенең статистика буенча дәүләт комитетының 2004 елның 23 гыйнварында кабул ителгән “Россия Финанс министрлыгы карамагындагы Гохран оешмалары өчен музейлар предметларында кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар булуны статистик күзәтү өчен статистик инструментарийларны раслау

турында"гы 6нчы карары (алга таба – РФ Госкомстат карары № 6);

Россия Федерациясе Мәдәният һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының 2007 елның 22 ноябрендә кабул ителгән "Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының Россия Федерациясе Музей фондының Дәүләт каталогын алып бару буенча дәүләт функциясен үтәү Административ регламенты раслау турында"гы 1320нче боерыгы (алга таба – Мәдәният министрлыгының № 1320 боерыгы) (Башкарма хакимиятнең федераль органнары норматив актлары бюллетены, 2008, № 30 кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендә кабул ителгән "Дәүләт контролен (күзәтү) һәм муниципаль контрольне башкарган вакытта юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында"гы Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру турында"гы 141нче боерык (алга таба – Россия Икътисади үсеш министрлыгының № 141боерыгы) (Российская газета, 2009, № 85, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Федераль дәүләт статистика хезмәтенең 2016 елның 7нче декабрендә кабул итлегән "Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы оешмалары өчен мәдәният оешмалары эшчәнлеген статистик күзәтү өчен статистик инструментарийларны раслау турында"гы 764нче боерыгы (алга таба – Росстат боерыгы № 764);

Татарстан Республикасының 1998 елның 3 июлендә кабул ителгән "Мәдәният турындагы" № 1705 законы (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 1998, № 7, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Татарстан Республикасының 2010 елның 14 октябрендә кабул ителгән "Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында"гы № 69-ЗРТ законы (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2010, № 10, 1203 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Татарстан Республикасының 2003 елның 12 маенда кабул ителгән "Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында"гы № 16-ЗРТзаконы (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 7, 685 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 18 августында кабул ителгән "Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре" (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыелмасы" журналы, 2005, № 33-34, 0772 бит, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып)".

1.5 пунктын түбәндәгечә язарга:

«1.5.Дәүләт контроле объектлары булып Татарстан Республикасы территориясендә булган һәм Россия Федерациясе Музей фондының федераль милектә яки Татарстан Республикасы милкендә булган дәүләт өлеше составына кертелгән музей предметлары һәм музей коллекцияләре булган музейлар һәм башка оешмалар санала (алга таба – тикшерү объекты).

1.7нең икенче пункты абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.10 пунктының "д" ярдәмче пунктын түбәндәгечә язарга:

«д) аны үткәргән вакытта тикшерү объектының җитәкчесе, башка вазифаи зат яки вәкаләтле вәкил булмаган очракта планлы һәм планнан тыш күчмә тикшерү үткәрергә, андый тикшерүне Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметлары һәм музей коллекцияләренә зыян китерү сәбәпле

үткәрелгән тикшерү искәрмә булып тора";

3.3 пунктын түбәндәгечә язарга:

"Мәҗбүри таләпләрне бозуны кисәтү максатларында Министрлык № 294-ФЗ Федераль законның 8.2 маддәсенең 5-7 өлешләре һәм РФ Хөкүмәтенең 166нчы карары белән расланган Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турындагы кисәтүләрне төзү һәм юнәлтү, юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан андый кисәтүгә кире кагу һәм аларны карау, андый кисәтүне карау турында хәбәр итү буенча чаралар күрүне һәм бу хакта Министрлык тарафыннан расланган вакыт эчендә хәбәр итүне күздә тота".

7.4 пунктын түбәндәгечә язарга:

Шикаятькә җавап түбәндәге очракларда бирелми, әгәр дә язма шикаятьтә гариза бирүченең фамилиясе (тикшерү объектының атамасы), җавап җибәрергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән очракта (әгәр дә аталган шикаятьтә законсыз гамәлләр кылыраг әзерләнү, кылыну яки кылу, яки аны әзерләүче, кылучы һәм кылган кеше турында сүз барган очракта, шикаять компетенциясенә карап, дәүләт органына җибәрелә).

Әгәр дә язма шикаятьне аңлап булмаган очракта (әлеге шикаять дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки вазифаи затка җибәрелә алмый, бу хакта җиде көн дәвамында шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә җибәрелә, әгәр дә аның фамилиясе (тикшерү объектының атамасы һәм почта адресны аңлап булган очракта);

Әгәр дә гариза бирүченең шикаятендә элек җибәрелгән мөрәҗәгатьләр буенча берничә тапкыр язма җаваплар бирелгән очракта һәм шул ук вакытта мөрәҗәгатьтә яңа сәбәрләр һәм дәлилләр китерелмәсә, министр чираттагы мөрәҗәгатьнең нигезсез булу һәм әлеге сорау буенча гражданин белән хат алышуны туктау турында карар кабул итә ала, тик әлеге мөрәҗәгать һәм алдагы мөрәҗәгатьләр шул ук орган яки шул ук вазифаи затка җибәрелгән очракта. Бу карар турында мөрәҗәгатьне юллаган гражданинга хәбәр ителә.

Әгәр дә язма шикаятьтә начар яки мыскыл итә торган гыйбарәләр, вазифаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының тормышы, сәламәтеге һәм милкенә, янаулар булган очракта министрлык яки вазифаи зат анда куелган сорауларны җавапсыз калдыра һшм мөрәҗәгатьне юллаган гражданга хокуктан явызларча файдаланырга ярамау турында хәбәр итә.

Шикаятьтә куелган сорауларга җавап биреп булмаган очрактагы сәбәпләр киләчәктә бетерелсә, гариза бирүче шикаятьне дәүләт органы, җирле үзиарә органы яки тиешле вазифаи азатка юлларга хокуклы.

Шикаятьнең соравына җавапны дәүләт яки федераль закон белән тыелган мәгълүматларны таратмыйча биреп булмаган очракта, мөрәҗәгатьне юллаган гражданга анда куелган сорауларга җавап биреп булмау турында хәбәр ителә.

Су карарына карата бирелгән шикаят теркәлгәннән соң җиде көн дәвамында шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә кайтарыла, әлеге суд карарына карата шикаять бирү тәртибе аңлатыла.".

**Министр** **А.М.Сибагатуллин**